Әлфия
Ситдыйкова

# Яктылык сулышы

Татарстан
китап
нәшрияты

Альфия Ситдикова

# Яктылык сулышы = Дыхание света

«Татарское книжное издательство»

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5

**Ситдикова А.**

Яктылык сулышы = Дыхание света / А. Ситдикова — «Татарское книжное издательство»,

ISBN 978-529-803391-6

Бу китапка шагыйрәнең төрле елларда иҗат иткән лирик-фәлсәфи әсәрләре туплап бирелде. Әлфия Ситдыйкованың хиссият диңгезендә йөзүче, Бәхет, Матурлык, Сөю һәм Наз эзләүче лирик-романтик герое ил һәм чор сулышын тоеп, үз туган халкы өчен яшьнәп яши.

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-529-803391-6

© Ситдикова А.
© Татарское книжное издательство

# Содержание


Офыгы киң, күге биек 6
Телем кирәк бүген кешеләргә 13
Чыныгу 13
Әйткән сүзем 15
Таяныргa нокта эзлим 16
Моң-зар тулы йөрәк 17
Аллы-гөлле дөнья 18
Шигырь җиле 19
«Ава-түнә, дөнья буйлап килә…» 20
Милләт бакчасында уйлану 21
Телне сатмыйк 25
Яралы җан 26
Уйдырма 27
Тарих өне шакый 28
Күкләргә менгән шагыйрь 29
Җил тарата 30
Мизгел кадере 31
Кемгә ничек 32
Ак һәм кара 33
Мираж 34
Заманага үтенеч 35
Көрәштән тора тормыш 36
Милләтчеләр 37
Йөгәнсезләр 38
Җаннан иман кача 39
Дөнья бетәр ул көн 40
Соңгы нокта 41
Нинди заман?! 42
Без әлегә исән 43
Милләт яшәр 44
Бүген әйтәм 45
Гомере җитмәс 46
Гомер үтеп бара 47
Суга күрмә теземә 48
Җәяүле җил 49
Вакыт килер беркөн 50
Төшкә керсә 51
Үзгәрми ул 52
Гомер арбасы 53
Яши шагыйрь 54
Язмыш эше 55
Тормыш йөге иңнәрдә 56
Җылым житә 57
Үз илемдә 58
Бер гомер 59
Бөркет моңы 60

«Мин ризамын, гомерем буе…» 61
Яшәргә өйрәттең 62
Моңнар чыңлый җанда 63
Конец ознакомительного фрагмента. 64

# Әлфия Ситдыйкова Яктылык сулышы. Шигырьләр, поэмалар, сонетлар һәм тәкълитләр

## Офыгы киң, күге биек

Әлфия Ситдыйкова… Аның исеме кайберәүләргә Чаллыда башланган яңа төзелешләр чорыннан ук таныш, күпләр исә аны шигърияткә соңгы унбиш-егерме елда килде дип исәпли. Әлфия Ситдыйкова тормышка, кешеләргә гашыйк, һәрчак елмаеп, балкып тора, бернәрсәгә дә битараф түгел, башкаларның хәленә кереп, ярдәм кулы сузарга әзер кешелекле ханым. Ул – йөрәк, мәхәббәт җырчысы. Шигърияттә заман болгануларыннан тәмам аптырап, чарасыз калган каләм ияләренең аһ-зарларын укып, шигъри зәвык зәгыйфьләнә башлаган чор иде. Мәхәббәт шигырьләрен яки мәхәббәткә багышланган (болар икесе ике нәрсә) шигырьләргә түбәнсетеп карау да сизелә башлаган чакта, Әлфиянең шигъри юллары сискәндереп җибәрде:

Минем җаным шигырь сулап яши,
Шигырь белән назга туена.
Килеп кердем ап-ак шигырь белән
Ак чәчәкле яшьлек туена.

Күп кенә каләми затлар: «Безнең тормыш гел кара төсләрдән генә тора, без инде аякка баса алмаячакбыз, безне котылгысыз һәлакәт, юкка чыгу көтә», – дип, үзләрен дә, башкаларны да ышандырып бетерә язган бервакытта, һәм, бәлки, иң кирәк вакыттадыр, Әлфия Ситдыйкованың аклык, сафлык, сөю тулы шигырьләрен укып, күңел түренә җылылык сирпелде, «дөнья гел кара төсләрдән генә тормый лабаса, анда мәңгелек кыйммәтләрне бар иткән мәхәббәт тә бар әле», – дигән уй сызылып үтте. Күңел офыклары яктыра, томаннар чигенә, күңелдә тансык хисләр уяна башлады.

Гүзәл язлар бүләк иттең миңа,
Яктырта ул гомерем иртәсен.
Минем өчен җирдә иң кадерле
Синең караш – илһам чишмәсе.

Мондый эчкерсез, тыенкы ашкыну, сөю-наз тулы юллар көйязарларны үзенә тиз җәлеп итте. «Синең караш – илһам чишмәсе» шигыренә Әлмәттә яшәп иҗат иткән, бик күп җырлар авторы Рәис Нәгыймов көй язды, һәм ул җыр күпләрнең күңелен яулап та алды. Альфред Якшимбетов, Мөдәррис Газетдинов, Илнур Фәйзуллин, Флүрә Талипова, Фәрит Миңлебаев һәм мине дә дистәләгән көй язарга илһамландырган иҗат бу!

Иҗатта Әлфия Ситдыйкованың үз юлы, үз укучысы бар. Ул шигырьдә беренче карашка гади, әмма күңелнең нечкә кылларын тибрәтерлек сүзләр тезә, кеше күңеленә сак кына шакып, пышылдап кына үз җанындагы иң яшерен серләрне дә ачып бирә. Ул – үз укучысын фикердәшенә әйләндерә алырлык серле шагыйрә. Чәчрәп чыкмый, кабаланмый, тота-каба башкалардан үз язганнарына ышануны таләп тә итми, аның дөньяны сөю призмасы аша кабул итүе төгәл, анык. Мондый поэзияне ничек үз итмисең ди! Шул ук вакытта укучы тоя: шагыйрәнең күңел капчыгында яшерен хисләре төрелгән шигырьләр дә шактый кебек, күңелендәге шәхси яра-әрнүләрне башкалар белән уртаклашасы урынга ул аларны һаман эчкәрәк бикләргә омтыла…

Кем ярасын кем дәвалар,
Җанга тоташ моң тулгач.
Җиргә килгән һәрбер кеше
Ул – яралы сандугач.

Һәркем тормышын үзе яза. Әлфия Ситдыйкованың иҗат язмышы хакында уйланганда, мин аның үзем белгән кадәрле тормыш юлын да күздән кичерәм һәм, шактый сынаулар үтеп тә, күңел байлыгын, хисләр муллыгын югалтмавына гаҗәпләнәм, нечкә сүз-хисләрдән тезелгән зәвыклы шигырьләр язуына сокланам.

Актаныш районы Күҗәкә авылында туып-үскән, югары белем алырга хыялланган кызны язмыш, Пучы урта мәктәбен тәмамлагач, Чаллы якларына алып килә. Әти-әни куеныннан аерылган мизгелләр һәркемгә таныш. Чит-ят җирдә сине беркем дә көтеп тормый. Туганың да, дустың да… Беренче мәлләрдә синең үз күңелең, үз уйларың гына. Кем хәленә кем керә? Синең белемгә омтылышың, әдәбиятка мөкиббән булуың, башкалар күзеннән яшереп кенә шигырьләр язуың кемгә хаҗәт? Ил башка уйлар, башка мәшәкатьләр белән яши. «Син, яшь кеше, алга партия куйган максатларны күтәрешергә тиешсең. Маяк – Павка Корчагиннар! Үзеңнең шушы токымнан булуыңны расларга тиешсең, бәбкәем», – дип, совет иле күзеңә тутырып карап тора бит. Шушы чакырулар, шушы тәрбия, гомумсовет тормышының бер винтигы буласы килү тойгысы күпләрне Чулман буендагы яшь калага китерә. Чаллы кайный, кая бакма – төзелеш, илнең бөтен тарафыннан җыелган бер-берсенә чит, әмма беренче очрашудан ук иң якын кешеңә әйләнеп куйган яшьтәшләрең, чордашларың, гамьдәшләрең барлыкка килә. Алар күбәйгәннән-күбәя, арткannan-арта. Чордашларың – КАмАЗ төзүчеләр, «кешеләргә яңа кала төзеп бүләк итүче» иң юмарт, иң тырыш буын вәкилләре. Дөнья кырыс, дөнья чуар. Аңлаешсыз омтылышлы сәер дөнья үзенә суыра, аң-зиһенне шигырьләр түгел, шигарьләр биләп ала. Диварларга язылган сүзләр керфекләрне каерып ача, күңелгә бәреп керә: «Даёшь..! Даёшь..! Даёшь..!». Яңа шәһәр, яңа заводлар комплексы, яңа йортлар, яңа машиналар… Боларның һәммәсен яшьләр бирергә тиеш. Әлфия менә шушы мохиткә килеп эләгә – тиз арада дизель төягече йөртүчесе һөнәрен үзләштерә, һәм егерме елдан артык автомобильләр төзү заводында эшли ул. Эшен яратып, тел-теш тидертмәслек итеп башкара. Мин үзем шушы заводта гади эшчедән участок башлыгы вазифаларын башкаручы дәрәҗәсенә күтәрелгән кеше буларак әйтәм: эшчеләр телендә «погрузчик» дип аталган бу машиналарда эшләүче кызларның КАМАЗ дигән машиналар чыгаруда хезмәте бик зур.

Күңелеңә Аллаһ Тәгалә иҗат очкыны салган икән, аны үзең дә сүндерә алмыйсың, башкаларның да кулы җитми. Әлфия, эшли башлап, тулай торакка урнашканнан соң ук, Чаллыда танылган «Ләйсән» әдәби берләшмәсе барлыгын ишетеп ала. Бәлки, тулай торакның «Кызыл почмагы»на Чаллыда яшәп иҗат итүче шагыйрьләр килгән булгандыр. Аларны күреп тыңлагач ук, кызның күңел түрен янә иҗат очкыннары яктырта башлагандыр. Шунысын беләм: 1975 елның көзендә Әлфия Ситдыйкова ул чакта әсәрләре газета-журнал битләреннән төшмәгән Мәхмүт Газизов, Хәниф Хөснуллин, Әхәт Гайнуллин, Ямаш Игәнәй, Рәйсә Фәхразиева, Фирая Хәлиуллина, Шәүкәт Гаделша, Венера Хәбибрахманова, Нәсыйх Таҗиев һәм башка бик күпләрнең тавышлары шаулап-гөрләп торган ләйсәнчеләр сафына килеп кушыла. 1978 елда шәһәргә Кадыйр Сибгатуллин килгәч, әдәби мохит яңа биеклеккә күтәрелә. Шигъриятькә, каләм иясенә булган караш та тамырдан үзгәрә. 1979 елда Татарстан китап нәшриятында «Яшьлегем Чаллы» исемле җыентык басылып чыга. Әлфия Ситдыйкованың берничә шигыре дә урын ала әлеге җыентыкта.

Мин һаман да шул авылча инде,
Тел-сөйләмем һаман шул көе.

Үзгәрмәгән шул ук елмаюым,
Шул ук икән моңнар сөюем.

Күренгәнчә, тәүге иҗат җимешләре үк «без Әлфия Ситдыйкова каләменнән» дип яктырып торалар. Ихлас, табигый, укучы белән күзгә-күз карап, тыныч, әмма хисси сөйләшү.

Әлфия Ситдыйкова шактый еллар әдәби мохиттән югалып торды. Кияүгә чыгу, балалар үстерү мәшәкатьләре, тормыш көйсезлекләре… Туксанынчы еллар… Завод эшчеләренә, төзүчеләргә бу елларда җиңел булмады.

Яңадан шигърияткә кайту авыр, һай авыр була. Әлфия Ситдыйкова каләмдәшләре сафына соңлап, бары ике меңенче еллар башында гына кабат килеп кушыла. аны шагыйрь итеп таныган, үсендереп торган Кадыйр Сибгатуллиннар буыныннан инде беркем дә калмаган. Бакыйлыкка күчкәннәр. Яңалар ышанмыйчарак кабул итәләр шагыйрәне. Каләм ияләре арасындагы элеккеге самимилек, иҗади аңлашу, туганлык хисләре сүнгән, мин-минлек көчәйгән… Чаллының әдәби мохите хуҗасы ташлап киткән йортны хәтерләтә. Менә шундый шартларда иҗатта үзеңне танытып кара!.. Әлфия Ситдыйкова Чаллы телерадиокомпаниясенең «Күңел» радиосына эшкә килә, әдәби тапшырулар оештыра, аларны халык яратып тыңлый. Соңлабрак булса да, яшьлек хыялы тормышка аша – Чаллы педагогия институтының филология факультетын тәмамлый. Рәшит Бәшәр, Факил Әмәк имзалаган сүз башлары белән бер-бер артлы китаплары чыга башлый. 2006 елда Казанда дөнья күргән «Назга сусау» китабына кереш сүзне Рәдиф Гаташ язган. «Бу китап, минем уемча, – гадәти булмаган, яңа, бер тыннан язылган – шикләнмичә әйтәм – бер сулыштан укыла торган мәхәббәт китабы, җан эзләнүләре китабы… Бу китап… ниндидер бер реаль яшәү, җир чынлыгы яки конкрет мәхәббәт тарихы түгел, ә бәлки нәкъ менә идеал булырлык Сөю эзләгән хатын-кыз җанының гаҗәеп серле, без белмәгән сихри көче чагылышы ул…» Халык шагыйре әйткәнчә, без, Әлфия Ситдыйкова шигырьләрен укыганда, иң беренче нәүбәттә аның әсәрләрендә күңелне тетрәндереп җибәрүче шушы «сихри көч чагылышына» игътибар итәбез дә инде. Әлфия Ситдыйкованың, бер карасаң, сагышлы, моңсу, икенче карасаң, ашкынулы, ниндидер серле дөньяга омтылышлы шигырьләренә игътибар итми мөмкин түгел. Алар – югары уку йортында шигырь теориясен өйрәнеп хисси ясалган, техник яктан бик оста үрелгән шигырьләр түгел, ә тормыш яздырган шигырьләр, кулына Ходай биргән каләм тарафыннан иҗат ителгән әсәрләр.

Әллә син адаштың, әллә мин адаштым,
Нигә соң очраштыра язмышлар?
Синең дә йөрәктә, минем дә йөрәктә
Гомергә җитәрлек сагыш бар.

Бу юллар «Язмышлар» шигыреннән, Флүрә Талипова аны көйгә салган. Җыр радио, телевидение аша еш яңгырый.

Яраттырган һәм яраткан өчен,
Хөкем итеп карар чыгарма.
Көлеп яшим, керфекләрем генә
Таң чыгыдай яшькә чылана…

Күпләр игътибар иткәндер, Әлфия – мәхәббәт шигырьләре язучы сирәк каләм ияләреннән. Мондый шигырьләрдә шагыйрәнең күңеле тулысынча ачыла, тартылу, наз, сөюдән баш югалту, оялчанлык… Ул интим хисләрне матур итеп, укучы күңелендә хисләр бураны кузгатырлык дәрәҗәдә оста итеп тасвирлый. Монда талымсызлык юк, монда кайнарлык, кеше табигатенең сөюдән илаһи биеклеккә чөелүе генә бар. Кешене мәхәббәт, ярату бар итә, ярату,

сөю булганда гына, кеше тормышы мәгънәгә ия. Ә сөю үзе – каршылыклы хисләр өермәсе. «Язмышлардан узмыш», «Җиде төн», «Назга сусау», «Сөю кошы» кебек күләмле шигырьләре, «Язмышлар ярында» поэмасы Әлфия Ситдыйкованың шигъри куәсе тирән һәм саллы, егәрле булуын, иркен сулышлы каләм иясе икәнлеген раслыйлар. Әлфия Ситдыйкованы мәхәббәт лирикасында үз тавышын ишеттергән, аны яңа биеклеккә күтәргән, башка төсмерләрдә ача алган лирик шагыйрь дип атарга тулы хакыбыз бар.

Бүләк-җәза язмышымнан миңа –
Бүген сөйдем, кичә сөелдем.
Боз-ялкынга төреп җылыттың да
Болыт булып алга түгелдең.

Мәхәббәткә табыну бер нәрсә, ә чын хисләрне зурлый белү, Рәдиф Гаташ әйткәнчә, «мәхәббәтне олылый» белү икенче нәрсә. Әлфия – чын сөю барлыгына ышандыра алган самими шагыйрә. Мәхәббәт хакында язарга дип кулга каләм алганчы, сорау туа торгандыр: бу гаҗәеп төгәллек таләп иткән темага ничек якын килергә? Күпләр моңа анык кына җавап бирә алмыйлар. Әлфия Ситдыйкова исә беләдер кебек. Юкка гына ул «Язмышлар ярында» поэмасына эпиграф итеп Оноре де Бальзак сүзләрен китермәгәндер: «Кешене бәяләр һәм хәлен аңлар өчен, ким дигәндә аның бәхетсезлегенә, кичерешләренә, аның серләренә үтеп керергә кирәк». «Буталган язмышлар» поэмасында шагыйрә чын сөю үрнәген сурәтли. Үзәктә – Мирхәйдәр белән Сәйдәнең мәхәббәте. Бу әсәр нигезендә фильм төшерәсе иде. «Ак чәчәкләр»дән ким булмас иде ул.

Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Утлы җимеш» (2011), «Тансык бәхет» (2012) китаплары Әлфиянең инде өлгереп җиткән шагыйрь булуын раcладылар.

Шагыйрь күңеле һәрчак эзләнүдә. Әлфия Ситдыйкова гади колхозчы гаиләсендә туган, ул – гади авыл кызы. Әтисе Мирзанур ага – балта остасы да, тирә-якта яшәүче кырыкка якын якташына йорт төзеп биргән кеше. Ул, 1943 ел башыннан Совет Армиясенә алынып, автоматчы, соңрак пулемётчы-артиллериячеләр батальонында радиотелеграфчы булып 6 ел солдат хезмәтен үтәгән, Япония милитаристларына каршы сугышта катнашып, илен яклаган ветеран. Тик, ни сәбәптер, аңа ветеран исеме бирелми. Авыл советында «архив янган» дип җавап бирәләр. Аның күкрәгендә чыңларга тиешле II дәрәҗә Ватан сугышы орденын Мирзанур ага үлгәннең икенче көнендә өйгә китереп тапшыралар. Ә ул шактый яшьли вафат була, гаделсезлекләргә әрнегән йөрәге түзми. Әнисенең бу орденны күкрәгенә кысып елавы Әлфиянең бүген дә күз алдында.

Тормышның төрле ягын күргән шагыйрәнең торган саен иҗаты киңәя, күтәргән темалары саллылана бара.

Көянтәләп сулар ташыганда,
Иңсәләрем шундый арый иде.
Бүген инде иңнәремә Каләм
Халык гамен, дөнья йөген өйде…

Иҗат кешесе кулына каләм алган икән, димәк, аның үзенә генә бирелгән вазифасы – ул гына башкарырга тиешле илаһи мәҗбүрияте – миссиясе бар. Каләм иясе шушы мәҗбүрияттән кача икән, димәк, ул шәхес буларак өлгереп җитмәгән. Әлфия Ситдыйкова дөнья күзенә туры карап яза: «Яңа көнгә аяк басам, / мең төрле уйлар уйлап». Туган җир язмышы да, ил, халык, милләт язмышы, туган телебезнең юкка чыгу чигенә җитеп баруы, читтә яшәүче милләттәшләребез тормышы – аны һәммә нәрсә борчый, ул болар хакында башкаларның җанына үтеп керерлек әсәрләр яза. Шагыйрь Туфан әйткәнчә, «әйбәт тынгысызлыкта» яши, иҗат итә.

Әмма шагыйрә каләмен өметсезлек чигенә китереп терәми. Киләчәккә, халкына булган ышаныч-иман – шигырьдә аның төп кредосы.

Егылсам да, туган туфрагымнан
Дәрман алып торып басармын.
Үги түгел, үз баласы бит мин
Сынмый яши торган татарның.

«Бетәбез» дип йөргәннәргә Әлфия рухи сабак бирә. Без бетмибез, «без яшәргә хөкем ителгән» (Равил Фәйзуллин). Бу фикер – аның иҗатының лейтмотивы. Күңелендәге яктылыкны замананың җил-давыллары сүндерерлек түгел, ул – көчле шәхес: «Тәрәзләрне җилләр каккан чакта, / Ябылмасын күңел капкагыз». Яки «Кешелекне саклап, Кеше булып / Кичик шаулы тормыш елгасын»… «Без бүгеннән уяныргa тиеш, / Уятырга тиеш күршене…» Манкортлашу тирәнгә төшсә дә, милләтнең үзеге исән: «Җаның әле саның эчендә». Санны сыйфатка әверелдерү – бүгенге вазгыятьтә авыр мәсьәлә, әмма мөмкин булмаган эш юк. Милләткә бердәмлек кирәк. Бу яктан без нык сынатабыз шул әлегә.

Менәселәр килә тау башына,
Бөркет кебек канат кагынып.
Әйткән сүзем калсын кешеләрнең
Күңеленә балдай ягылып.

Тормышны кабул итәргә өйрәнергә кирәк. «Сүнми янган гомер учагының / Көле дә бит шундый кадерле». Бүгенге кайбер уңышсызлыклар, күңелсезлекләрне төзәтеп булмас дип уйласак, үл дә кит. Егылмаска, яшәргә кирәк. Үзе дә уяныргa, башкаларны да уятырга тиеш каләм иясе. Татарда үрнәк алырлык батырлар, көчле затлар күп: «Көчлеләргә карап, алга атлыйм, / Көчлеләрдә – халык хәтере!» Әлфия Ситдыйкова да – көчлеләр токымыннан. Тик ул – шагыйрь, аның җаны үтә нәзберек, табигате үтә нечкә: «Мин – бу юлда адашканнар өчен / Юл күрсәтеп үскән бер гөлең». «Ишетерләр беркөн аклык теләп / Күз яшьләрем аша дәшүне»…

Әлфия Ситдыйкованың туган авылы Күҗәкә – борынгы авыл. Ул зур мәдрәсәле, укытубелем бирү үзәге буларак тирә-якта дан тоткан. Күҗәкә мәдрәсәсен тәмамлаган шәкертләр, Уфага барып, имамлыкка имтихан бирү хокукына ия булганнар. Шушы якның суын эчеп үскән шагыйрәнең туган ягына ихтирамы чиксез:

…Белмәгәнмен кайда туасымны,
Кайчан туасымны, кем булып.
Тик мин тоям, тамырлардан ага
Бабамнардан калган моң, тулып.

Әнкәсе Гөлсем апага атап язган шигырьләрендә дә Әлфиянең күңеленә салынган моңнарның чыганагына тап булабыз. «Авылның Акъәбие» дип йөрткәннәр Гөлсем апаны. Авыл кырыс, әмма гадел хөкем йөртә. Бу изге исемне һәркемгә дә бирми ул.

Халык җырын җырладың син безгә,
Атап түгел, тик эш арасында.
Боекканда юатты да ул җыр,
Дәвалады йөрәк ярасын да.
Рәхмәт, Әнкәй, сиңа барысы өчен…

Туган ягында каты җил исеп китсә дә, Шагыйрәнең күңелен кузгата. Туган ягы – Актаныш төбәге өчен Әлфия җан атып яши. Туган ягына багышланган шигырьләре, җырлары байтак аның. Бернинди ясалмалылык, ярарга тырышу юк аларда. 2007 елда Актаныш өстеннән гарасат үтә. Давыл иген басуларын, агачларны актарып ташлый. Шагыйрә, давылның юктан купмавын әйтеп, сәбәпчесе битарафлык булуын, халыкның, дөнья мәшәкатьләренә чумып, милләт гамен югалтуын күрсәтә, мәхшәр аша халкына эндәшә («Давыл тавышы»). Бу давыл кисәтү булып кабул ителә. Битараф яшәүне дәвам итсәк, тагын да аянычлырак хәлләргә тап булуыбыз бар. Бу кисәтү һәркемгә кагыла:

Туфан купмас борын уян, халкым,
Ач күзеңне, берүк соңлама!
Ишетәсеңме, агач тамырын кочып,
Җир-анакай үкси, сызлана.

Бүгенге авылның хәле аяныч. Шагыйрә кабат-кабат авыл темасына әйләнеп кайта. «Үлмә, авыл!» балладасы авылның гөрләп торган чакларын искә төшерә. Лирик герой берәм-берәм авылдашларын барлый. Кино кадрларыннан үткән төсле, Кендек әби, Хатыйп абыйлар, Сәгыйдә апа, Гариф абыйларны күреп калабыз. Инде алар мәңгелеккә күчкәннәр. Онытылып баралар. Һәркайсының язмышы – үзе бер тарих. Авыл кешеләрен җуя, моңнарын оныта. Яңа, ят көйләр урамнарны кыйнап үтә:

Дөмбер-дөмбер итеп, заман көе
Бәреп үтә безнең чигәгә.
Таныш моңнар түгел, чит-ят аваз
Килеп керә җансыз өйләргә.

Авылдан яшьләр киткән, киләчәккә өмет какшый. Авылны чолгап алган ямьле табигатен барлап йөри шагыйрә, басу-кырларны иңли, эш осталарын хәтерендә яңарта. Боларны авылдан бизгән яшь буынга ничек тапшырырга?

Барла, хәтер, барла үткәнеңне,
Ялга аны килер буынга.
Чайка аңны, чистарынып китсен,
Чайка көмеш чишмә суында.

Шушы ук тема «Киләчәгең кайда, Кешелек?», «Күмер базы» поэмаларында тагын да үстерелә. Авылның бетү сәбәпләре тирәнтен ачыла, аны саклап калу, кешеләрен барлау, аларны авыл хәтеренә беркетеп калу зарурлыгы искәртелә. Авыл бетү – милләтнең, телнең юкка чыгуы түгелме?..

Үз телендә дәшә алмый күпләр
Үзе гомер биргән балага.
Бүген кайсы татарны син алма –
Мескенлеккә барып ялгана.

Үткән гасырның илленче елларында яшь парларга, өйләнешү белән, налог салына торган булган. Ит, йон, йомырка, сөт салу, хәтта акчалата да түләүләр булган… Әмма яшьләр өйләнешә торалар… һәм читкә чыгып китәләр. Барысының да теләге бер: тормыш яхшыргач, акча туплап, туган якларга кайтырбыз. Әмма чынбарлык икенче шул… Әлфия Ситдыйкованың

«Күмер базы» поэмасын укыганда сискәнеп куясың… Балалар туа, руслашып үсәләр. Шахталар төзелеше көрчеккә терәлгән, инде мондагы шәһәрләр дә үлеп бара. Мәңгелеккә киткәннәр гомуми зиратка күмелә… мөселманча күмелгәннәрнең дә рухлары тыныч түгелдер…

Зират бер дә, кыйблалары башка –
Татар, урыс кабере рәттән.
Ярымайга каршы, мәрмәр ташка
Урыс побы тәре терәткән…

Шулай да авылларны кайбер фидакяр затлар саклап кала әле. Яңа йортлар салына, аларга карап, өмет уяна: «Күрәсезме! Ирексөяр бүген / Яңа йортлар сала авылында»… Авылны яшәтү өчен көрәшкә күтәрелүчеләргә рәхмәтебез чиксез.

Әлфия Ситдыйкова – үзен поэма жанрында сынап караган һәм бу өлкәдә уңышларга ирешкән, бүгенге күзлектән караганда, сирәк шагыйрьләрнең берсе. Шигырь язучылар күп дибез, аларның язганнары, шигырь булудан бигрәк, шигъри парчаны хәтерләтәләр. Поэма кебек фикер киңлеген сораучы, күп көч таләп итә торган, чиксез иҗат потенциалы барлыкны раслаучы жанрга егетләр эше дип караучылар бар иде. Инде хәзер андыйлар да сирәгәя. Әлфия Ситдыйкова – дистәдән артык поэма язган шагыйрә. Лирик-фәлсәфи стильдә, озын тезмәләр түгел, ә конкрет сюжетлы, гомумиләштерүләр белән, образ-персонажларның эш-гамәлләрен күрсәтеп, төрле символ, сурәтлелектә лирик накалны югалтмыйча, тасвирда эздән чыкмыйча, нык кул белән эпик планда язылган әсәрләр алар. Шагыйрә сәяхәт итәргә ярата. Шуның нәтиҗәсе буларак, татар поэзиясенең офыгын киңәйтерлек яңа әсәрләр туган. «Абай илендә», «Кырым көндәлекләре» кебек әсәрләрен күз алдымда тотып әйтүем. Ул һәр әсәрендә укучыны күз уңында тота, һәр шигыре, поэма, балладасы укучы белән сөйләшү төсмерен ала. Шуңа күрә дә шагыйрәнең күңел дулкыны укучыныкы белән тәңгәл киләдер. Төрле очрашуларда аның шигырьләрен яратып тыңлыйлар, китапларын сорыйлар. Иҗат кешесенең бәхете менә шул инде.

*Факил Сафин, филология фәннәре кандидаты*

# Телем кирәк бүген кешеләргә



## Чынығу

Үр менгәндә каршылыклар булса,
Үпкәләмим бер дә язмышка.
Күрәселәр күктә билгеләнгән,
Табышлар да, хәтта ялгыш та.

Көрәшләрдә, димәк, чыныга-чыныга
Яшәр өчен, җиргә килгәнмен.
Шөкер итеп кабул итәм шуңа
Тәкъдир язган һәрбер бүләген.

Сөенәм мин һәрбер аткан таңга,
Һәрбер көнгә, һәрбер мизгелгә.
Мин яшәгән һәр көн – ул минеке,
Һәр минутын яшим үземчә.

Киртәләрне ватып үтәр өчен,
Рухи көч тә өстәп бирелгән.
Сукмагыма яуган яфракларга
Алтын йолдыз диеп үреләм.

Рәхмәт, язмыш, каршылыклар белән
Сыныйсың син минем ныклыкны.
Җиңелү һәм җиңү барын аңлап,
Чыныктырып яшим холыкны.

# Әйткән сүзем

Яшәү – үзе олы бер могҗиза,
Кирәклегең тойсаң һәркөнне.
Яшьни алсаң яшен уты булып,
Чикләмәсәң уйда иркеңне.

Җылы сүзең ятка кызганмыйча,
Дәрман өсти алсаң күңелгә,
Шул мизгелдә дөнья бер могҗиза,
Тылсым булып күзгә күренә.

*

Кемнәрнедер, кипкән яфрак төсле,
Җил иркенә куя язмышы.
Ә кемнәрдер давылны да җиңә,
Читкә этеп куеп ялгышны.

Офык белән офык арасына
Чигеп үрә затлы бизәкләр.
Гомер-тауның иң очына менә
Шуңа күрә җирдә сирәкләр.

Менәселәр килә тау башына,
Бөркет кебек канат кагынып.
Әйткән сүзем калсын кешеләрнең
Күңеленә балдай агылып.

# Таянырга нокта эзлим

Таянырга нокта эзлим җирдә,
Дөньясы киң, тормыш катлаулы.
Алга барам томан ера-ера,
Җиңел түгел әмма атлавы.

Нокталар күп, таяныйммы дисәм,
Әйләнә дә куя өтергә.
Мин тырышам, җебен чуалтмыйча,
Гомер йомгагымны сүтәргә.

Таянырга нокта эзлим җирдә,
Йөрәгемне кысып кулыма.
Дөрләп янган өмет учагыннан
Якты сибелә барыр юлыма.

# Моң-зар тулы йөрәк

Сынар өчен яралткандыр Ходай
Җиргә килгән һәрбер баласын,
Каш белән күз якынлыгы иткән
Яшәү белән үлем арасын.

Ялгышлар да булган, кем генә соң
Хаталардан хали була алган?
Адәм белән Һаваны да Ходай
Җәннәт бакчасында сынаган.

Бу дөньяның барлык моң-зарларын
Җыя-җыя йөрәк түремә,
Сындырмыйча сабыр канатымны,
Менеп киләм гомер үремә.

# Аллы-гөлле дөнья

Көне-төне юк-бар уйлап йөрим,
Вак-төяккә уем бәйләнгән.
Азмы-күпме авыз итеп яшим
Ачы-төче сыек әйрәннән.

Аркылыга-буйга йөреп иңлим
Аллы-гөлле хыял дөньясын.
Аллы-арты килсен борчу-шатлык,
Ут-суларга төшү булмасын.

Иртә-кичем аклы-каралы да,
Кайчак күрмим акны-караны.
Азмы-күпме аркылыга-буйга
Үлчәп йөрим ике араны.

Тормыш дәвам итә алга таба,
Кайта-китә хыял иленә.
Дөнья күзләп тора яшәвемне,
Таянган да нечкә биленә.

# Шигырь җиле

Тәрәзәмне җилләр килеп какты,
Тойды йөрәк ялкын сулышын.
Кайсы гасыр җиле ниләр сөйли,
Болгый-болгый хәтер кылычын?

Җилнең телен аңлар ачкычымны
Күңел эзләп тапты ишектән.
Кол Гали һәм Тукай, Хәсән Туфан,
Мөдәррисләр сүзен ишетәм:

«Гасырлардан килгән мирасыбыз
Югалмасын, – диләр, – саклагыз!
Тәрәзләрне җилләр каккан чакта,
Ябылмасын күңел капкагыз.

Шигырь җиле булып исәбез дә
Халык хәтерен шулай барлыйбыз.
Ачыгыз сез тәрәз-ишекләрне,
Исән булса әгәр җаныгыз!»

# «Ава-түнә, дөнья буйлап килә…»

Ава-түнә, дөнья буйлап килә
Җил-буранлы усал зилзилә.
Ачык-тишекләрне барлый-барлый
Бер елый да, аннан бер көлә.

Көч-куәтен җигеп, зыян-зәвер
Салып уйный, иңләп җиһанны.
Әйтерсең лә җирдә туфан купкан,
Җен-пәриләр баскан дөньяны.

Елап-сыктап җирдә ауный җилләр,
Моңлы-зарлы үксү тавышы.
Тынсыз-өнсез итәр бер мизгелдә
Үзәкләрне өзәр сагышы.

Күк күкрәтеп, дөбер-шатыр килеп,
Коеп ява көчле яңгыр да.
Кырып-себереп, бөтен шакшылыкны
Тели, ахры, юып алырга.

Иксез-чиксез дөнья буйлап чаба
Җил-буранлы усал зилзилә.
Вату-җимерү иң зур максатымы,
Чистарыну микән, кем белә?!

# Милләт бакчасында уйлану

## 1

Ничәмә кат өмет алданды да,
Ничәмә кат җаннар таланды.
Кичәге көн бүген таный алмый
Бишегеннән төшкән баланы.

Намус, вөҗдан дигән төшенчәләр
Күмелеп калган кара тузанга.
Кул селтәгән гасыр мең ялгыштан
Сабак алмый чорлар узганга.

Сугышлардан, шартлаулардан гына
Җуйганмы соң Җирем баласын?!
Сулыш алуыннан мәхрүм итеп,
Җәллад утка илтеп салмасын.

Акча – патша. Тормыш итү – уен.
Йозаклар нык, ачкыч югалган.
Ачы көлү тавышы ишетелә
Колхоз корган шанлы еллардан.

Булдыклылар – кулак… Сөрелделәр
Үз иленнән, салган өеннән.
Бүре булып аваз салды иблис,
Теш ыржайтып тишек өненнән.

Ачлык белән миллионнарны кырды,
ГУЛАГларга илтеп черетте.
Буйсынмаганнарны, утка салып,
Кайнар чуен кебек эретте.

Шахталарда күмер тузанына
Батып калды күпме уллары.
Ишелде баз, өмет коткармады,
Сузылганда өскә куллары.

Кыйммәт башка хәзер. Кемдер өстә,
Астагылар һаман таптала.
Тарих битен ачкан һәрбер көннең
Эчтәлеген бизәп, тап кала.

Ак тапларны кемнәр аңлатыр соң
Алмаш булып килгән буынга?

Татар бүген ятлар казанына
Койган канда госел коена.

Унберенче елның июль ае.
«Булгария» Идел төбендә.
Йөз егерме ике кеше гомерен
Тартып алды әҗәл бер көндә.

Туар өчен яралганнар китте,
Бер гөнаһсыз сабый балалар.
Чәчен йолкып, яр буенда үкси
Балаларын җуйган аналар.

Яр буйларын чәчәкләргә төреп,
Күпме генә көтеп йөрсәң дә,
Берсе дә бит кире кайта алмый,
Фәрештәләр сулыш өрсә дә.

Бу – кисәтү язмыш тарафыннан,
Җан айнытыр өчен чакыру.
Күпме дәвам итәр сүзсез үксү,
Ләгънәт укып, бушка аһ ору?..

Тик бер генә кеше гаеплеме,
Илебезгә килгән казага.
Без вөжданны сукыр бер тиенгә
Саттыкмы соң әллә базарда?!

Милли аң да төшеп калган баштан.
Урыслашты тел вә каныбыз.
Үлмәс борын тере мәет булдык,
Каңгырып йөри җирдә җаныбыз.

…«Локомотив» очты. Кырык өч җан
Җир тартуны җиңә алмады.
Бер секундта хоккей командасын
Газраилнең авызы ялмады.

Ахырзаман галәмәтеме бу?!
Төркем-төркем үлә кешеләр.
Азгынлыгы өчен җәмгыятьнең,
Югалтулар өчен кем түләр?!

Түләүчеләр – очын-очка ялгап
Көн күрүче, белә һәммәбез.
Тормыш арбасына ат җиккәнче
Сынган ласа ныклы тәртәбез.

Йөгән кидермәгән гомер атын

Иблис алган, ахры, җитәкләп.
Хәлдән тайган атлар дөнья буйлап
Алга атлый, әмма титаклап.

Егылганчы йөгәнләргә кирәк
Һәм җигәргә кирәк арбага.
Бардыр әле аек акыл белән
Алга караучылар арада.

Шул ышаныч шартлап сынмасын да,
Өметләрне җилләр екмасын.
КЕШЕЛЕКНЕ саклап, КЕШЕ булып,
Кичик шаулы тормыш елгасын.

## 2

Барлыгымны шигырь биләп алган.
Минем гомер үтә иҗатта.
Вакыт җитәр, Ходаемның әмере
Калебемне төрер хиҗапка.

Ә әлегә ил язмышы һәм дә
Халкым язмышына борчылып,
Көткән мәлем, яткан таш астыннан
Саф чишмәнең чыгуын ургылып.

Тарих катламнарын ачып карыйм,
Күрер өчен килер көннәрне.
Бар милләтләр тигез хокук яулар,
Үстерерләр туган телләрен,
Дигән хыял чынга ашар диеп,
Ышанучы инсан затыннан.
Ианнуым юлдаш итеп, армый
Барам алга заман артыннан.

## 3

«Без ирекле!» Шушы ике сүзне
Кабатлаган канлы иреннәр.
Күтәрелгән халкым ничә тапкыр,
Котылмаган коллык чиреннән.

Тәнгә генә түгел, җанга сеңгән
Курку хисе ага тамырдан.
Күпме кеше нәфес колы бүген –

Байлык, акча, данга табынган.

Без яшәгән илдә кыйбла башка,
Таңнар ата бездә саташып.
Без төзегән коммунизм чоры
Чал тарихта калган адашып.

Без – тоткыннар. Богаулар да бүтән.
Гореф-гадәт күптән үзгәрде.
Сизмәгәнбез, басып алган инде
Ак тап безнең ачык күзләрне.

Иксез-чиксез тормыш диңгезендә
Без – бары тик дулкын баласы.
Нишләтсә дә язмыш, төпкә батмый,
Су өстендә килә каласы.

**4**

Ялган белән ялгау мөмкин түгел
Үткән белән килер көннәрне.
Тарихны да кабат яза күпләр,
Алдап-йолдап үзен, меңнәрне.

Үз ялганы белән үзен үзе
Буып ала аннан, белешми.
Ә чынбарлык өскә калкып чыга,
Ялган белән җаны килешми.

**5**

Ирек эзли җаным. Сусаган аң
Баш калкыта өзеп тынлыкны.
Очар өчен туган гамьле затлар
Иш италмас һич тә коллыкны.

Күк күзеннән җанга баккан ирек
Иңгә куя талмас канатын.
Хөрлек яулар өчен, асыл затлар
Эшкә җиксә булган талантын.

# Телне сатмыйк

Сатылып бетте бар да –
Ил дә, җир дә…
Барысы да булды алыпсатар.
Бүген телен сукыр тиенгә сата
Манкортлашып беткән һәрбер татар.

Үз аңы юк, башканыкы керми,
Кабул итми фикерен кешенең.
Әнә тагын берсе үзе белән,
Упкын авызына якынлашкач,
Дустын аска сөйрәп төшерде.

Кими бара татар, хәрәм ашап,
Үсә бара аның бүксәсе.
Җәһәннәмгә туры юл алганда,
Пеләшләнеп беткән башы төсле,
Ялтырап кала бары үкчәсе.

Сатылып бетте бар да…
Сатасы да,
Аласы да юк бу дөньяда.
…Тишек чүлмәк кенә эленеп калган
Хыял белән койган коймада.

# Яралы җан

Кадерсезләр яшәгән ил баласына
Бетмәс газап – тоз сибелү ярасына.
Ирексезләр җиһан буйлап атлый алга,
Әллә артка, рухлары сына-сына…

Кайда бакма, җаны гарип күзгә карый.
Буш караштан дөнья бүген кемне таный?!
Кеше канын имеп бүксә үстергәннәр
Көнне төнгә ялгый-ялгый акча саный.

Мескенлеккә дучар булган җан нишләсен,
Ирек диеп дәшәр иде – тел тешләнгән.
Алга бармый гомер аты – туктап калган,
Имелеп, изелеп яшәгәнгә, ул өшәнгән.

Солы да юк, салам да юк инде алда,
Баш очында каркылдаша кара карга.
Каргалган ил, таланган ил, җанын ачып
Бәргәләнә бүген текә кыя ярда.

Күтәрелер көч табармы, илем әллә
Тәгәрәрме төпсез упкын кочагына?
…Яралы җан, ирек сорап, таң кошыдай
Канат җилпи зәңгәр хыял кочагында…

# Уйдырма

Торгын заман. Дөрес яшәлмәгән.
Үткәннәр бит бар да ялган булган.
Төкерделәр тарих китабына,
Ул төкереккә ил язмышы сыйган.

Кем ялгышы, кемнең саташуы
Безнең башка күсәк булып төште?
Башны гына түгел, җаннардагы
Кыяларны җимерә тетрәү көче.

Дөрес яшәлмәгән… Уйдырмага
Ышандымы «көчле» һәм «зур» халык?
Чәбәләнә тозактагы сыман,
Юл тапмыйча чытырманда калып.

Иске өйне сүтеп утка яктык,
Ә яңасы әле төзелмәгән.
Заманаы үзгәрер дип көткән
Күңелләрдә өмет өзелмәгән.

Пыскып яна тычкан уты кадәр
Нәни генә бер шәм безнең җанда.
Яшәү өчен көрәшергә өндәп,
Аз булса да, дәрман ага канда.

# Тарих өне шакый

Күкне томалаган күксел болыт
Кай тарафтан безгә килгәндер,
Бәлки, инде күптән без югалткан
Болгар дигән изге илдәндер?..
Телне, илне, гореф-гадәтләрне
Яңартырга теләп хәтердә,
Тәрәзәне шакый көзге яңгыр:
– Үткәннәрне барла, кадерлә!
Гасырлардан урап кайткан тарих
Өне шакый безнең аңнарны.
Гомер елгабызның юлы чикле,
Килер буын безне барлармы?!
Күкне томалаган күксел болыт
Уйчанланып бага күзләргә.
Табигатьнең телен аңлый башлый,
Кергәч кеше бары көзләргә.

# Күкләргә менгән шагыйрь

*9.12.2011 ел. Фәнис Яруллин мәңгелеккә китте*

Җилкәнен җилләр сынады, тик Шагыйрь сынатмады.
Ил алдында намусын ак саклады, югалтмады.
Халык шагыйре булды ул, таланты – сынмас канат:
«Яшәсәң, шулай яшә һәм яратсаң, шулай ярат!» –

дип дәлилләде һәркөнне, ярату, сөю көчен –
Бу җиргә туган шагыйрь ул, шуны исбатлар өчен.
Яшәде халык өчен ул, мең тапкыр утта көеп,
яшәде кызларны Мәҗнүн, Таһирдан артык сөеп.

Батырлык һәм сабырлыкның үрнәге булды бит ул,
яткан килеш тә күрсәтте милләткә туры, киң юл.
Күңелендә Өемташ тау горурлыгы бар иде,
күкләргә менде уенда, җиһан аңа тар иде.

Ык елгасы ярсуларын җанында саклап калды,
Һәр язганы укучысын тирән уйларга салды.
Җырлары аша таралды бар кыйтгаларга даны.
…Тарсынды дөнья читлеген, тарсынды бугай җаны.
Ак кышка сары төс иңде югалту сагышыннан,
кош талпынып канат какты хушлашу тавышыннан.
Очты китте. Шагыйрь җаны кочадыр хур кызларын,
шигырьләре басар, бәлкем, милләт җаны сызлавын?!

Татар җаны сызлавын?..

# Җил тарата

Ялкынланып утта яна
чорга язган хатларым,
җил тарата төтен итеп
хыялларның акларын.
Офык читенә илтә җил
йөрәктә туган моңны,
тилергән күк, сөрем сөзеп,
уфылдап ала тынын.
Яна-яна тарала моң иркен,
киң җиһан буйлап,
әллә җырлап, әллә көлеп,
әллә сулкылдап елап,
яңа көнгә аяк басам,
мең төрле уйлар уйлап…

# Мизгел кадере

Саулыкның кадерен беләсең,
Сихәтлек киткәндә тәнеңнән.
Савыга башлыйсың, дустыңнан
Җылы сүз ишеткән мәлеңнән.

Яшәүнең мәгънәсен төшенми
Сүтелә гомернең йомгагы.
Аңлыйсың кадерен мизгелнең,
Калдырып киткәндә дөньяны.

# Кемгә ничек

Бәхет белән бәхет аермасы –
Кеше белән кеше арасы.
Кемнәргәдер мизгел бәхет бирә,
Кемнәргәдер – күңел ярасы.

Кемдер аңлый бәхетне җыр итеп,
Кемдер риза йотым суга да.
Кемдер соңлап таный үз бәхетен,
Тормыш гөле өшеп сулганда.

Бәхет белән бәхет аермасы –
Кеше белән кеше арасы.
…Һәрбер көнем үтсен шатлык белән,
Калдырмыйча йөрәк ярасы.

# Ак һәм кара

Ачы хакыйкатьне танып беләм,
Хакыйкатькә генә ышанам.
Кырыкмаса кырык кабат уем
Дөреслеккә килеп тоташкан.

Авыздан ут чәчү ярдәм итми,
Аермасаң акны карадан.
Акка кара таммас, аккош җыры
Ак юл теләп очса арадан.

Караңгыда тимерказык була,
Юлын таба һәрчак ир заты.
Язылып куйган акка кара белән,
Туганчы ук, язмыш китабы.

# Мираж

Мираж булган инанганым –
Син дә башкалар сыман.
Җаныңа ваклык, көнчелек,
Хөсетлек мулдан сыйган.

Ишелде хыял таулары –
Арада упкын, бушлык.
Төше черек чикләвекне
Сакламый каты тышлык.

Үземнән артык ышандым,
Сокландым ничә еллар.
Чын йөзең ачтың, күңелдә
Зыңлап өзелде кыллар.

# Заманага үтенеч

Үтермә, заман, үтенәм,
Үтермә туган телне.
Зир-зәбәрдән[1] йолып кал син
Зиннәтле милләтемне.
Телсез калса, милләт үлә,
Илләр дә юкка чыга.
Яфрак койган, тамыры кипкән
Агачлар җилдә сына.
Тамырсыз калган агачка
Тиңләмә милләтемне.
Кодрәтең киң, и замана,
Сакла син туган телне!

[1] Җимерелү, актарылу, асты өскә килү.

## Көрәштән тора тормыш

Беләбез лә, дус дип йөргән бәндәнең дә
Тышы алтын, эче тулы кара елан.
Адашканда караңгыда, шәм урынына
Кулыңа ул суда яткан чыра сузган.

Киңәш кирәк чакта аңа килсәң әгәр,
Шундый итеп бирә белә ул җавабын.
Тик бирүзең күтәрәсең иңнәреңдә
Илләр белән күтәрерлек җан газабын.

Дошман диеп читләп үткән бәндәләр дә
Ихлас ярдәм иткән чаклар бик күп була.
Шул мизгелдә хәлдән тайган күңелеңә
Яшәү дәрте өсти торган ак нур тула.

Ак һәм кара көрәшеннән тора тормыш.
Караларын ак итәргә үзең тырыш!
Сынауны да итә алсаң олы табыш,
Хак Тәгалә язар сиңа якты язмыш.

# Милләтчеләр

«Татар халкы! Син үләргә мәхкүм инде…» –
дип язсаң да, бөек Тукай, ышанмадым.
Тиберченеп, милли аңым эшкә җигеп,
Алып аттым җаннан заман тышауларын.

«Милләтчеләр сине фәкать алдый гына…» –
дисәң дә син, өмет әле исән килеш.
Бирешмәдем акча сузган кемсәләргә,
Нәфесемне җиңә-җиңә җырлап килеш.

«Терлер өчен корбан кирәк…» дигәндә дә,
Ак намусны сатмадым мин ваклап-ваклап.
Коръән-Кәрим аятьләре – таянычым,
Кылган эшем – үз халкымның хакын хаклау.

«Милләтче бик куркак бит ул, судан курка…»
Авыз суын корытучы күптер күбен.
Илем өчен суга төшкән чакларда да
Батмый чыктым, тешем кысып түзсәм түздем.

«Алданмыйча, газиз башың кабергә керт…»
Алданмаска тормыш үзе сабак бирде.
Арт сабакны укытса да усал язмыш,
Баш имәгәч, якын итеп кочты билне.

Шик-шөбһәгә бирешмәсәк, кем генә соң
Туры юлдан яздырырлык көчкә ия?!
Милләт өчен янып-көеп яшәгәннәр
Алдында бер тарих үзе башын ия.

Буш эшләргә вакытыңны сарыф итсәң,
Корсак хакын хаклау булса бар максатың,
Баш куйганчы ләхетеңә, синнән алда
Хак алдына барып җитәр яманатың.

Котылу юк хак тәңренең җәзасыннан,
Ахыр чиктә һәммәбезне тигезли ул.
Халкы өчен тырышып хезмәт иткәннәргә
Аллаһ насыйп иткән сукмак – оҗмахка юл.

# Йөгәнсезләр

Холкы ямьсез, йөгәнсез ат сыман,
Үтә таптап хәтта җаныңны.
Йөзең ерта, гайбәт чәчә җилгә,
Бер тиенгә сата даныңны.

Йөдәтә ул сине өндә, төштә,
Уңда, сулда, алда, артыңда.
Йөрәгеңә потлап тоз да сала,
Җәлләми ул яшен, картын да.

Ерак йөртсен Аллаһ шундыйлардан,
Фәрештәләр берүк сакласын.
Ә әрсезләр безне дөньялыкта
Беркайчан да эзләп тапмасын.

# Җаннан иман кача

Бетә инде татар иле, диләр,
Лаф оралар, зарга күмәләр.
Үзгәргәнгә милләт язмышлары,
Гаепләме бары түрәләр?!

Кем карарын үтәп, сүзен тотып,
Самими һәм садә балага
«Әни» сүзен «мама» дип әйттерә,
Теләге соң кемгә ярарга?

Гөлбикәләр күптән Галя инде,
Мәснәвиләр – Миша, Михаил.
Авылында җир хуҗасы булса,
Шәһәрдә бит бары гидай ул.

Ата-ана кушкан исемнәрен
Ятлар бозды, дәшә алмады.
Иблис токымына башын иде,
Этеп куйды читкә Алланы.

…Яратмаслар, ни әйтерләр, әгәр
Үз телеңдә һаман сөйләсәң…
Җаннан иман кача, җылылык та
Бетә икән, белми өләшсәң.

Яраклашу татар кавеменең
Сеңгән микән әллә канына?
Сукырларча табынумы соң бу
Олы абзый, урыс халкына?

Шәһәр йота, йотып тора һаман,
Төпсез авыз йота авылны.
…Суалчаннар эзләп, чүплек саен
Тибенеп йөри авыл тавыгы…

# Дөнья бетәр ул көн

Тукай кайтып әгәр күзен салса
Замананың кара йөзенә,
Дөнья булып, дөнья бага алмас
Шагыйренең яшьле күзенә.

«Милләтем!» дип җанын фида кылган
Тукай инде халкын танымас,
Милли моңны инде элеккечә
Дәва итеп җанга ябынмас.

Телен, илен, динен саткан кавем
«Шыр ялангач» басар каршына,
Оялмыйча: «Милләт үзен үзе
Сатты, дияр, җитте башына!»

«Ник тереклдем?!» Аһ орыр да шагыйрь,
Йөрәккәе шартлап ярылыр,
Милләт тамыры корып беткән язлар
Шагыйрьнең дә соңгы языдыр.

Дөнья бетәр ул көн. Һәм Җир шары
Күчәреннән очып чыгар да
Кайтыр кабат, «Милләтем!» дип янып,
Тукай шигырь язган чорларга.

# Соңгы нокта

Аттай җигелеп,
  эшләп хәлдән тайдым, –
дип уфтанма әле
  юкка да.
Эт көнедәй
  каһәрләгән язмыш
Көтәр булса
  соңгы ноктада,
Үкенерсең,
  чәчләреңне йолкып
Еларсың да,
  бәлки, карганып.
Дөнья малы –
  дуңгыз каны ич ул,
Яши күрмик
  берүк алданып.

Гомер хакың
  күпме тора, бәндәм?! –
Аңла шуны
  тормыш иткәндә!
Беркем үзе белән
  берни алмый,
Мәңгелеккә
  күчеп киткәндә.
Өч аршын
  җир көтә…
Өч аршын
  җир җитә…

# Нинди заман?!

Күзле күрми, колаклылар ишетмиләр,
Иш итмиләр канатлылар канатсызны.
Сүзләр генә эретә алмый күңелләрнең
Ишекләрен каплап алган каткан бозны.

Күптән инде бар канунны бозып-җимереп,
Вакытларны кире борган заман килде.
Кем туктатыр көчкә ия, бармы берәү,
Кешелеккә каршы искән давыл-җилне?!

Җирне афәт каплаганны күргәннәр дә
Таш кыяга менеп баскан, күзен йомып.
Җирем, Илем, Телем, газиз Халкым минем,
Башны ташка орыйммыни инде сынып?

Кабат-кабат чын ирләрне барлый күңел,
Гаме барның һәр кешедә эше дә бар.
Калган эшкә кар яудырмас ирләр туса,
Дөньялыкны каплый алмас зар-интизар.

Кар яуганны көтеп тормыйк, уяныргa
Вакыт җитте, йокладык без бик тә озак.
Канат кага якты өмет, тере әле,
Кешелекнең хәтеренә элмик йозак.

# Без әлегә исән

*«Кычкырырга,*
*Эш кырырга*
*Вакыт җитте, Татарстан!»*

*М. Әгъләмов*

Чын шагыйрьләр үлми, яши бирә
Иле, теле, дине хакына.
Милләт аңын шакый үткәннәрдән,
Чиксезлектән дәшә халкына:
«Тураерга, зураерга вакыт,
Авыз иттең, – диеп, – яңарыштан.
Ач йөзеңне, әйт сүзеңне, – диеп, –
Вакыт җитте, – диеп, – Татарстан!»
Мәңгелектән дәшә, нәгърә ора,
Җанын ачар өчен милләтнең.
Үлемсезләр мәрткә киткәннәргә
Аңлатадыр ирек кыйммәтен.
Без әлегә исән. Яңарышның
Башын күргән, тәмен татыган.
Ишетергә тиеш бу дәшүне,
Уяныргa тиеш йокыдан.
Без күрергә тиеш дәвамын да,
Эш кырырга тиеш бүгеннән.
Безнең милләт аерылмаска тиеш
ТУКАЙ теле, АНА теленнән.
Без яшәргә тиеш…
Без яшәргә хаклы…

## Милләт яшәр

Безне тотып тора Ана теле,
Милләт яшәр, балаң тел белсә.
Телебезне җуйсак югалырбыз,
Юкка чыга халык, тел үлсә.

Төп байлык ул – безнең нәселебез.
Рухи ныклык – сөйләр телебез.
Сәнгатебез, җыр-моң, әһле китап,
Башкаларга әйтер сүзебез.

Без эзләргә тиеш шушы сүзне,
Җиткерергә тиеш халыкка.
Язылмасын «беткән милләт» дигән
Яман сүзләр язмыш-ярлыкка.

# Бүген әйтәм

Сабыр ит син, диләр. Сабыр булып,
Инде күпме гомер яшәлгән.
Тәнне ташлап, җаным сәфәр китсә,
«Илем!» – диеп бер сүз дәшәлмәм.

Түзем булу кирәк, диләр дә бит,
Ничә гасыр түзгән татарым!
Милләт әгәр бер көн юкка чыкса,
Ничек тыныч йоклап ятармын?

Җан әйләнеп кабат җиргә кайтыр,
Ялганырга милләт җанына.
Сабыр итмим, бүген әйтәм сүзем
Җандай якын күргән халкыма.

# Гомере җитмәс

Кыска гына гомер яшәсә дә,
Әверелеп якты йолдызга,
Каләм белән Тукай бөтен татар
Халкы өчен туры юл сыза.

Сатсалар да Печән базарында,
Сатылмаган мәкер, ялганга.
Гасырларга онытылмаслык исеме
Шигырьләре аша ялгана.

Һәрбер язган сүзе шигыренең
Коръән аятенә тиңләрлек.
Ничә гасыр яшәсә дә татар,
Гомере җитмәс әҗерен түләрлек.

# Гомер үтеп бара

*«Тормышның кыска икәнен исеңдә тотып яшә».*
***Гораций***

Телне кисеп, әйтер сүзен өзеп,
Типмәгәндер читләр артына.
Телне телгә кушып, сүзне бозып,
Яши никтер яше-карты да.

Яраклаша татар, анасын да,
Баласын да сата, кызганмый.
Дөнья куа, алтын-көмеш җыя,
Милләт диеп җаны сызланмый.

Гомер үтеп бара, сизелми дә…

# Суга күрмә теземә

Чынбарлыкны онытасы килә,
Онытмырмый тормыш минут та,
Канат куя кайчак иңбашыңа,
Йә биетә сине ул утта.

Кайгылардан сынам дигән чакта,
Дөнья көлеп карый күзеңә,
Каеннарның тузларына кадәр
Мохтаҗ икән язар сүземә.

Суга күрмә, тормыш, теземә…

# Җәяүле җил

Җәяүле җил урам буйлап атлый,
И сөйләшә кайчак шым гына.
Йә эт сыман өреп, улап ала,
Йә тукталып уйлый тын гына.

Җәяүле җил, этә-төртә, күрче,
Атлап бара үзәк урамнан.
Җил иркенә бирелгәннәр, кулын
Сузып, хәер сорый буранда.

Җәяүле җил әрсез, кочагыңа
Атылып керә кинәт, сораусыз.
Җиде җилнең җиде өне җанда,
Җиде төштәй, ләкин юраусыз.

Тугарылган җәяүле җил йөри,
Дөнья буйлап бәрелеп-сугылып.
Җил тавышы җанга кереп кала,
Мәңге тынмас гамьле уй булып…

# Вакыт килер беркөн

Сөяр өчен яратылган җаным бүген
Ил гаменә баткан көйгә уйга талды.
Сандугач та сайравыннан тына, диләр,
Сынган чакта басып сайрар зифа талы.

Көн тууга, эшсезлек-чир күзгә бага.
Өметсезлек кулы җанга тамга сала.
Илдәшләрең сыкранганда, күңелдәге
Сайрар кош та җырын өзеп тынып кала.

Әле анда, әле монда кара хәбәр:
Кем кул салган түзалмыйча үз-үзенә.
Арты белән терәделәр диварларга,
Ничек баксын баласының күзләренә?

Ирләр кулы дилбегәне ычкындырды,
Соңгы чиктә бауны сайлый чарасыздан.
Күптән аны этеп-төртеп төшерделәр
Замананың каретасы – «барабыздан».

Үлемгә дә күнектеме әллә бу ил?
Сыктауларга инде беркем колак салмый.
Көне-төне радио сөйләп тора
Арта, диеп, илдә эшсез халык саны.

Әйтерсең лә сөенече эчкә сыймый,
Ике түгел, ун мәртәбә кабатлыйлар.
Кая барып бәрелергә белмәгәннең
Җанын телеп, һаман-һаман газаплыйлар.

«Ун кешене кыскарттык…» – дип, беркем дәшми,
Берәүгә эш биргән үзен йөз кат мактый.
Каршы дәшсәң, тиз кыскарта телеңне ул,
Җиргә салып, итек белән җаның таптый.

Рәхәт илдә рәхәт чигеп яши халык.
Сусыз җирдә йөзеп йөри алтын балык.
Дилбегәне кулга тоткан мыек майлап
Көлеп тора: «Халык, – диеп, – аңгыра сарык».

Белми әле башлы тинтәк ирек кошы
Таң каршылау өчен канат кагынганын.
Вакыт кулы беркөн килеп тартып алыр
Ялган-мәкер белән сырган одеялын.

## Төшкә керсә

Төштә күргән өндә алга килә…
Күрәзәче түгел түгелен.
Тик шулай да, ни буласын алдан
Сизеп тора минем күңелем.

Өметләрнең киселеп төшүләре
Уелып калган яшьлек мәлендә.
Читләр ничек сине үз итсен дә
Уе белән керсен хәлеңә?!

Кешенеке кештәктә, дип, халык
Хак сүзләрен әйткән күптәннән.
Төшкә кергән алга килә икән,
Бу алхәбәр, димәк, үткәннән.

# Үзгәрми ул

«Дөнья кая бара?» – дип сорыйбыз,
Без барабыз дөнья артыннан.
Күпме җаннар бәргәләнеп ята,
Егылып төшкәч гомер атыннан.

Дөнья бармый, кеше чабып бара,
Мәңге куып тотмас булса да.
Гомер узып, кыйналудан сынып,
Күңел әрнеп, җаны тузса да.

Куа кеше мал һәм дан артыннан,
Ваклый-ваклый һаман үз-үзен.
Дөнья көлә: «Куып тоталмассың.
Халык – балык, ач, дип, ач күзең».

Үзгәрми ул дөнья, шул ук килеш,
Тик без генә никтер үзгәрәк.
Китеклән күңел, уйласак та
Дөнья, диеп, барыбер түгәрәк.

Кем өчендер чите кителгәндер,
Кем өчендер дөнья – куласа.
Кем шатлана һәрбер туган көнгә,
Кем моңая, уйлар уйласа.

Кешелекнең йокымсырап яткан,
Тәмле төшләр күргән сәгате.
Дөнья шул ук, безне үзгәрер дип,
Югалтса да күптән тәкатен.

Без куабыз дөнья артыннан…

# Гомер арбасы

Җиргә яшәр өчен киләбез дә,
Яши белми китеп барабыз.
Туган көннән алып ахыргача,
Шыгырдавык тәгәрмәчен сынап,
Тәгәри лә тормыш арбабыз.

Майланмаган арба тәгәрмәче
Көпчәгеннән төшеп калганчы,
Иманына тугры калмый бәндә,
Коры вәгъдә бирә, ялганчы,
Арбасыннан төшеп калганчы.

Үзен үзе алдый: «Иртәгәдән
Билләһи, ди, шиксез, үзгәрәм.
Үзем үзгәрмәсәм, бу дөньяны
Теләгәнчә көйлим, үзгәртәм».
Моң агыла, никтер, күзләрдән.

Үзгәрергә җитми көчебез дә,
Тәгәри, һай, тормыш арбасы.
Вакыт җитә, юктыр бер чарасы,
Тиздән инде төшеп каласы,
Шыгыр-шыгыр гомер арбасы…

# Яши шагыйрь

Янып яшәр өчен туа шагыйрь.
Җанын иңләп, давыл кузгала.
Йөрәк уты сүнгән чагында да,
Утлы күмер булып сүз кала.

Яши шагыйрь, ялкынланып янып,
Үзе түгел, халкы өченгә.
Һәм таяна тарих төпкеленнән
Агып чыккан шигырь көченә.

Китә шагыйрь. Күпме кешеләрнең
Күңеленә җылы сүз салып.
Белеп китә, җырга күчкән гомере
Гасырларда калмас югалып.

# Язмыш эше

Алу белән кушулардан тора гомер…
Алуы да, кушуы да – язмыш эше.
Алган чакта: «Тәкъдир», – диеп сабыр итә,
Кушкан чакта: «Шөкер!» – әйтеп яши кеше.

Бүлгән чагын күргәнем бар ялгышларның
Кыл икегә тәкъдир язган язмышларны.
Бөлгән чакта, хәтер барлый берәмтекләп
Гомер буе эзләп тапкан табышларны.

Алу белән кушу гына түгел гомер…

# Тормыш йөге иңнәрдә

Хатын-кыз итеп яраткан
Туганда мине Ходай!
Хак Тәгаләм, кичер мине,
Ир булып яшим бугай.

Табылмады тормыш йөген
Тартышыр якын кешем.
Хатын-кыз булып тусам да,
Башкарам ирләр эшен.

Сыенып минем иңемә,
Яшәргә тели ир-ат.
Хатын-кыз булып яшәргә
Кайчан соң тияр чират?!

Инде кызым, минем кебек,
Ил йөген салып җанга,
Хатын-кыз булып туса да,
Ир булып атлый алга.

Хатын-кыз итеп яраткан
Туганда аны Ходай.
Хак Тәгаләм, кичерә күр,
Ир булып яши бугай.

Үзебез Ана булсак та,
Ата да булу кирәк.
Ир булып үтә гомерләр…
Шартлама берүк, йөрәк!

# Җылым җитә

Һәр гариф[2] не зурлап башым идем,
Горурланып алдым киңәшен.
Гарипләргә ярдәм кулым суздым,
Хәләл малым, җылым өләштем.

Бисмиллалап көнне башлаганга,
Аермады сыйдан-хөрмәттән.
Аңлап, белеп яшим, тәм-ямь табам
Ходай сые – тырыш хезмәттән.

[2] Акыл иясе, тирән фикерле кеше.

# Үз илемдә

Чит илләрне шактый күп күргәннәр
Күп йөргәннәр диңгез артына.
Ә мин менә бөтен бер җанымны
Бүлә алмыйм ике яртыга.

Үзем гомер иткән Ватаныма
Береккәнмен ныклап тумыштан.
Үз илемдә тугры халкым белән
Тәм-ямь табып яшим тормыштан.

Алтын таулар эзләп сәфәр чыкмам.
Шатлыкларым итә канатлы.
Учларыма җыеп ил шатлыгын
Җырлар итеп йөрим таратып.

# Бер гомер

Туулар бар җирдә, китүләр бар,
Китми яшәү мөмкин түгелдер.
Туу да бер җирдә, китү дә бер,
Гомерләр дә безнең бердәнбер.

Яши белеп яши алсак җирдә,
Булмас иде кайгы-газаплар.
Ялгышлыклар кылсаң, кайтавазы,
Кайтып кире, күпме яңаклар?!

Бер абынган өчен мең кат түләп
Тормыш итә кеше чынлыкта.
Бер кабынган учак, дөрләп янып,
Ныклык өсти икән холыкка.

Бер мизгеллек бәхет өчен күпме
Еллар белән түләп әҗерен,
Бер гомерне яшәп китә кеше,
Аңламыйча аның кадерен.

Яши белеп яши алсак иде…

## Бөркет моңы

Бөркет һәрчак күккә күтәрелә,
Кыяларда була оясы.
Оя корган кыя җимерелсә,
Ялгыз башны кая куясы?!

Усал җилләр канатларны каерып,
Каурыйларны йолкып алганда,
Яра тулы кош йөрәге әрни,
Сыкрап-сыкрап, кайнар кан тама.

Сулар һава җитми, оя тузган,
Ничек түзсен бөркет кайгыга?!
Таштай атыла упкын авызына,
Шаһит була тулган ай гына.

Һаваларда канат каккан юлы
Сызылып кала ап-ак томанда.
Ирек сөйгән бөркет кошның моңы
Яңгырый бүген яңа җырларда.

# «Мин ризамын, гомерем буе…»

*Мин ризамын, гомерем буе*
*Шигырь булып яшьнәсәм.*
*Ике гомер кичерәсең,*
*Шигырь сулап яшәсәң…*

*Лена Шагыйрьҗан*

Минем җаным шигырь сулап яши,
Шигырь белән назга туена.
Килеп кердем ап-ак шигырь белән
Ак чәчәкле яшьлек туена.
Минем сулыш – шигырь сулышы ул,
Сулыш алам халкым өчен дә.
Гомер юлым – һәрбер язган юлда,
Яшәү көчем – шигырь көчендә.
Минем җаным шигырь сулап яши,
Яшәешем минем – шигырьдә.
Язмыш язган бәхетемне таптым
Шигырь белән үргән гомердә.

# Яшәргә өйрәттең

Дөньяны аңларга,
Дусларны барларга,
Сыгылмый, бөгелми,
Сер бирми ятларга,
Сайлаган сукмактан
Тайпылмый атларга,
Тапканны югалтмый
Кадерләп сакларга,
Өр-яңа җыр булып
Яшәргә бу җирдә
Өйрәттең, и Тормыш!
Урадың мең сергә.

# Моңнар чыңлый җанда

## (сонет)

### 1

Кара төс тә кайчак җанга якын,
Ул да бизәк-чигеш аклыкка.
Тормыш та бит түгел гел саф алтын,
Ак-карадан тора хаклык та.

Табигатьтә төсләр алышына,
Яз артыннан килә ямьле җәй.
Торна моңы! Гомер агышына
Ак карлардан кышка җәймә җәй!

Назлап сыйпый кулым балаларның
Ефәк кебек кара чәчләрен.
Җилләр сөртеп ала болытларның
Түгелергә торган яшьләрен.

Искәртә лә чал чәчләрнең төсе –
Көтә алда гомеремнең көзе.

### 2

Моңнар чыңлый җанда, моңнар чыңлый…
Гомер агып бара тын гына.
Күпме сагыш минут тынында.
Чаларган карт дәвер шавын тыңлый.

Яшьлек белән картлык очрашкан мәл,
Дулкын белән дулкын кушылган,
Югалттым, дип, язган һушыннан.
Узган гомеркәйләр бигрәк җәл.

# Конец ознакомительного фрагмента.

Текст предоставлен ООО «ЛитРес».

Прочитайте эту книгу целиком, купив полную легальную версию на ЛитРес.

Безопасно оплатить книгу можно банковской картой Visa, MasterCard, Maestro, со счета мобильного телефона, с платежного терминала, в салоне МТС или Связной, через PayPal, WebMoney, Яндекс.Деньги, QIWI Кошелек, бонусными картами или другим удобным Вам способом.